**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 34** **2015 елның 16 июнь**

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендә кабул ителгән 42 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 декабрендә кабул ителгән 42нче карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Түбән Кама муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «в) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре), ул үзе, аның хатынының (иренең) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларының белешмәләр тапшыру елыннан алда торган календарь ел дәвамында башкарган чыгымнары турында белешмәләрне, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, әлеге алыш-бирешләрне алу чыганаклары хакында;

1.2. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «13. Муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары) сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчалар чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып китсә, хисап чорына кадәр, законда каралган тәртиптә Түбән Кама муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, ә бу мәгълүматлар рәсми сайтта юк икән, аларның запрослары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла».

2. Әлеге үтәлешне контрольдә тоту җирле үзидәрә, регламент, хокук саклау сораулары буенча даими комиссиягә тапшырырга.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин